КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2020 ел, 15 сентябрь | г.Казань | № 828

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналы редакциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмага Татарстан Республикасы законнары җыентыгын чыгару белән бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1006 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналы редакциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмага Татарстан Республикасы законнары җыентыгын чыгару белән бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналы редакциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмага Татарстан Республикасы законнары җыентыгын чыгару белән бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1006 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 29 декабрь, 1121 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналы редакциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмага Татарстан Республикасы законнары җыентыгын чыгару белән

бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле 1[1] нче пункт өстәргә:

«1[1]. Субсидия «2014 – 2022 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 17 декабрь, 1000 нче карары белән расланган «2014 – 2022 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасы кысаларында Татарстан Республикасы законнары җыентыгын бастырып чыгару максатларында бирелә.»;

2[1] нче пунктта:

беренче абзацта «субсидия күләме» сүзләрен «субсидия күләме (С)» сүзләренә алыштырырга;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

җиденче абзацта «тарату» сүзен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 2[2] нче пункт өстәргә:

«2[2]. Субсидия түбәндәге юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла торган чыгымнарны каплауга бирелә:

штаттагы һәм штаттан тыш хезмәткәрләрнең эш хакын түләү һәм аларның хезмәте өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр;

бюджеттан тыш фондларга иминият кертемнәрен, җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминият буенча кертемнәрне, дәүләт пошлиналарын, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри бүлеп алып калынган суммаларны һәм түләүләрне түләү;

типография һәм полиграфия хезмәтләре күрсәтү, алып килеп бирү (транспортлау) (мәҗбүри нөсхәсен кертеп) чыгымнары өчен түләү;

бүлмәләрнең арендасы өчен түләү, техник чаралар сатып алу, коммуналь хезмәтләр, элемтә хезмәтләре күрсәтү, программа тәэминаты (бухгалтерлык программалары, вируска каршы программалар, электрон хисаплылык) өчен чыгымнар, белешмә-мәгълүмат базаларын яңарту, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдалану;

интернет-сайтны карап тоту һәм аның эшләвен тәэмин итү буенча хезмәтләр күрсәтү өчен түләү;

канцелярия һәм чыгым материаллары, инвентарь, офис техникасы сатып алу, аңа хезмәт күрсәтү (ремонтлау) чыгымнары;

авторлык һәм чиктәш хокуклар буенча түләүләр (архив материалларыннан, компьютер графикасыннан файдалану чыгымнарыннан тыш);

редакция чыгымнары;

банк хезмәтләре күрсәтү өчен түләү.»;

3 нче пунктның дүртенче абзацында татар текстында «үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процессында түгел» сүзләрен «үзгәртеп оештыру, бетерү процессында түгел» сүзләренә алыштырырга, «бетерү процессында түгел» сүзләреннән соң «, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, оешма эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаган;» сүзләрен өстәргә;

3[1] нче пунктның тугызынчы абзацында «исәп-хисап кәгазьләре» сүзләрен «эш хакын исәпләүләр һәм аннан тотып калулар җыелмасы» сүзләренә алыштырырга;

6 нчы пунктта:

унбишенче абзацта «вакытлары» сүзен «тәртибе, вакытлары» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнгән өстәмә хисаплылык бирү вакытлары һәм формалары;

субсидияләр бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе.»;

7 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Килешү белән күздә тотылган чыгымнарның күләмнәре кимегән очракта, субсидия күләмен үзгәртү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма буенча субсидия бирү турында өстәмә килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирү турындагы килешүгә өстәмә килешү проекты чыгымнарның күләмнәрен кимету турында мәгълүмат бирелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә оешмага җибәрелә.

Субсидия бирү турындагы килешүгә өстәмә килешү оешмадан аның ягыннан имзаланган өстәмә килешү алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә вәкаләтле орган тарафыннан имзалана.»;

8 нче пунктта:

«вакытларда» сүзен «тәртиптә, вакытларда» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия бирүнең нәтиҗәсе булып елына кимендә сигез чыгарылышта бастырып чыгарылган «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы» журналлары саны тора.»;

түбәндәге эчтәлекле 8[1] нче пункт өстәргә:

«8[1]. Субсидиядән файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү вәкаләтле орган тарафыннан әлеге килешүдә күрсәтелгән һәм субсидия бирү нәтиҗәсенең ирешелгән мәгънәсен чагыштыру нигезендә гамәлгә ашырыла. Бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турындагы хисап субсидия алучы тарафыннан вәкаләтле органга хисап чоры тәмамланган вакыттан 30 көн эчендә кәгазь чыганакта тапшырыла. Субсидия биргән айдан соң килә торган өченче ай хисап чоры булып тора.»;

9 нчы пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучы тарафыннан вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган, субсидия биргәндә билгеләнгән шартларны бозганда;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«бу Тәртипнең 8 нче пунктында күрсәтелгән нәтиҗәләргә ирешмәү.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

«Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналы редакциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмага Татарстан Республикасы законнары җыентыгын чыгару белән бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибенә кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 15 сентябрь, 828 нче
карары редакциясендә)

Форма

20___ елның __________ хәленә карата «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналы редакциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмага Татарстан Республикасы законнары җыентыгын чыгару белән бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында
хисап

Субсидия алучының исеме: ________________________________________

Тапшыру вакыты: ________________________________________________

| Т/с | Нәтиҗәнең исеме | Үлчәү берәмлекләренең гомумроссия классификаторы буенча үлчәү берәмлеге | | Нәтиҗәнең план буенча мәгънәсе | Хисап датасы хәленә карата нәтиҗәнең ирешелгән мәгънәсе | Планны үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | исеме | коды | | | | |
| 1. | Бастырып чыгарылган журналлар саны | | | | | | |

Субсидия алучының җитәкчесе
(вәкаләтле зат) __________________ ___________ ______________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

Башкаручы __________________ ______________________ ___________________
(вазыйфасы) (Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда)) (телефоны)

20__ ел, «___» ___________

__________________________